**СОВЕТ ЕКАТЕРИНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423196, РТ Новошешминский район с. Сл.Екатерининская, ул. Приовражная д. 9.
тел.: (8-4348) 3-67-36, факс: (8-4348) 3-67-36

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕКАТЕРИНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423196, РТ Яңа Чишмә районы ,
Екатерина авылы, Приовражная урамы, 9
тел.: (8-4348)3-67-36 факс: (8-4348) 3-67-36

Тел.: (8-4348)3-67-36, факс (8-4348)3-67-36 Ekat.Nsm@tatar.ru.

КАРАР КАРАР

2020 елның «30» октябреннән № 2

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Екатерина авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22,81 статьяның нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлеге башлыгы

карар кабул итте**:**

1. 2020 елның 29 ноябренә сәгать 10.00да, Луговая урамы,7 йорт янында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылындагы Луговая урамы,1-14 йортларда яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 29 ноябренә сәгать 11.00да, Үзәк урам,23 номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылындагы Үзәк урамның 1-28 йортларында яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020 елның 29 ноябренә сәгать 12.00да, Үзәк урам,1А номеры буенча урнашкан Яңа Иванаево авылы мәдәният йортында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылындагы Үзәк урамның 30-69 һәм Яшьләр урамы йортларында яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Гражданнар җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителәә.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыннары, 1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Яңа Иванаево авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып

алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

Юл урам челтәрен норматив холго китерү (смета нигезендә юл төзү: сатып алу, күчәреп йөртү, вак таш салу, нигез әзерләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) Үзәк һәм Яшьләр урамы урамнарын тоташтыручы тыкрыкны төзү;

- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт курсәтүләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

9. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылының мәгълүмат стендында урнаштырырырга.

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Екатерина авыл җирлеге Башлыгы А. А. Хорьков